**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 17.03.2020** **№291**

**Биектау муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы мобиль отряд төзү турында**

Хайваннарның һәм кошларның куркыныч авырулары таралу чыганакларын локальләштерүгә һәм аннан соң юкка чыгаруга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы чаралар комплексын үткәрү максатында, 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турындагы» Федераль законны, 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы «Ветеринария турындагы», 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турындагы» Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Биектау муниципаль районында территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд (ары таба – отряд) оештырырга һәм аның составын расларга (1, 2 нче номерлы кушымталар).

2. Биектау муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды җитәкчесе итеп «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ начальнигы И.Р. Вәлиевне билгеләп куярга.

3. «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ башлыгы И.Р. Вәлиевкә:

3.1. түбәндәге документацияне әзерләргә һәм раслауга тапшырырга:

отрядның оештыру-штат структурасы;

отрядның шәхси составы исемлеге;

отряд составына кертелгән автомобиль һәм махсус техника исемлеге;

отрядның шәхси составына хәбәр итү системасы схемасы;

отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм аны җыю буенча отрядның дежур торучысы инструкциясе;

3.2. Биектау муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының шәхси составын ветеринария белгечләре белән тупларга һәм отрядның профильле төркемнәрен җиһазлау нормасы буенча мөлкәт һәм техника белән тәэмин итәргә.

4. Биектау янгын-коткару гарнизоны башлыгы А.Ф. Кәлимуллинга тиешле документларны эшләүдә Биектау муниципаль районының эпизоотиягә каршы даими әзерлектәге мобиль отряды һәм «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе»

ДБУсе җитәкчесенә методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтындагы: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.  веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
«Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 нче елның 17 нче мартындагы
291 нче номерлы
Карары белән

**Биектау муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә (Африка чумасы, кошларның югары патогенлы гриппы, себер түләмәсе, котыру авыруы һ.б.) эпизоотияләре белән бәйле килеп чыккан кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авыруларның таралу чыганакларын локальләштерүгә һәм бетерүгә, аларның нәтиҗәләрен минимальләштерүгә юнәлдерелгән эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядларын куллануның гамәли тәҗрибәсе нигезендә гадәттән тыш хәлләрне (алга таба - ЧС) локальләштерү һәм бетерү буенча эпизоотик чаралар комплексын үткәрү максатыннан, әлеге Нигезләмә Биектау муниципаль районының (алга таба – муниципаль берәмлек) эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядны (алга таба – отряд) оештыру һәм эшләтү тәртибен билгели.

Отряд штаттан тыш оешма булып тора һәм Биектау муниципаль берәмлегендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының карары нигезендә оештырыла.

Отряд составында төзелә торган функциональ бүлекчәләрнең (төркемнәрнең, звеноларның, расчетларның һ.б.) якынча саны Биектау муниципаль районы карары белән раслана.

Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турындагы» Федераль законына» (03.07.2019 үзгәрешләр белән), 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турындагы» Федераль законына (26.07.2019 үзгәрешләр белән), 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы «Ветеринария турындагы», 1995 нче елның 4 нче декабреннән 13-7-2/469 номерлы Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләренә, Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы Министрлыгының 2016 нчы елның 31 нче маендагы 213 нче номерлы «Африка дуңгыз чумасы таралуны булдырмый калуга һәм чыганакларын бетерүгә юнәлдерелгән профилактикалау, диагностика, чикләү һәм башка чараларны, карантин билгеләү һәм кире алу һәм башка чикләүләрне гамәлгә ашыруның ветеринария кагыйдәләрен раслау турындагы» боерыгына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының кешеләрнең иминлеге,

хайваннарның (кошларның) авыруларын профилактикалау, авыру чыганакларын юк итү өлкәсендәге башка норматив-хокукый актларына, Африка дуңгыз чумасы (кошларның югары патогенлы гриппы) авыруларының Татарстан Республикасы территориясенә үтеп керүен һәм таралуын булдырмау буенча республика штабы карарларына, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясе күрсәтмәләре, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

Отряд "Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ белгечләре, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең Татарстан Республикасындагы Арча һәм Биектау районнары буенча территориаль бүлеге (килешү буенча), Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының биологик ресурслар буенча Биектау бүлеге (килешү буенча), «Татарстан Республикасында (Татарстан) Арча һәм Биектау районнарында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗ филиалы (килешү буенча), "Биектау ҮРХ" ДАССУ, Россия ЭЭМ Биектау районы буенча бүлеге һәм Россия ЭЭМ Биектау районы буенча юл хәрәкәте иминлеге буенча Дәүләт инспекциясенең бүлеге (килешү буенча), Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге, исәпкә алу һәм хисап бүлеге, Россиянең Татарстан буенча 113 ПСЧ 7 ПСО ФПС ГПС ГУ МЧС белгечләре исәбеннән формалаша.

Отряд расланган план нигезендә дәвалау, ветеринария-санитария, эпизоотиягә каршы, эпидемиягә каршы, чикләү (карантин) һәм башка чаралар комплексын үтәүне гамәлгә ашыра.

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча, йогышлы учакта эшләр башкару чорына, отрядның барлык шәхси составына эпидемик күрсәткечләр буенча ашыгыч иммунопрофилактика үткәрелергә тиеш.

## II. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды бурычлары

Отряд Биектау муниципаль районы территориясендә кошларның (хайваннарның) авыруы ситуациясен контрольдә тоту, шулай ук эпизоотияләр һәм (яисә) хайваннарның һәм кошларның кошларның һәм хайваннарның йогышлы булмаган этиологияле массакүләм үлүе (авыруы) белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексын үтәү максатларында төзелә.

Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә.

Беренче этап – авыру кузгатучының төрен (яки кешеләрнең авыру сәбәпләрен һәм хайваннарның (кошның) күпләп үлү сәбәпләрен ачыклаганчы.

Икенче этап — авыру төре ачыклanганнан һәм ахыргы диагноз куелганнан соң.

Беренче этапта отрядның бурычлары:

ветеринария һәм медицина разведкаларын гамәлгә ашыру;

эпидемиологик һәм эпизоотик хәлне бәяләү

контактта булган, зәгыйфьләнгән һәм авыру хайваннарны (кошларны) (ары таба – авыру хаайваннарны (кошларны) тоту;

үлгән, клиник авырулы хайваннардан (кошлардан) патологик материал алу;

тикшеренүләр уздыру өчен махсус лабораторияләргә пробалар китерү;

җиһазларны, инвентарьны бүлмәләрдә һәм территориядә агымдагы дезинфекцияләүне үткәрү;

биналарны һәм территорияләрне механик рәвештә чистарту үткәрү.

Икенче этапта отрядның бурычлары:

гадәттән тыш хәл (карантин) зонасында тәүлек буе үткәрү режимын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

гадәттән тыш хәл (карантин) зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү;

гадәттән тыш хәл (карантин) зонасындагы халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

бөтен авыру хайваннарны (кошларны) тоту һәм йоклатып юк итү (эвтаназия) һәм кирәк булганда сәламәт хайваннарны (контактта булган) хайваннарны (кошларны) юк итү;

үлгән һәм үтерелгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү (юк итү) урыннарына китерү;

үлгән һәм үтерелгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү;

эпизоотик учакны бетерүдә катнашучы отрядның һәм башка затларның шәхси составын санитар эшкәртү;

бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү;

агымдагы һәм соңгы дезинфекцияне үткәрү;

хайваннарны һәм башка мөлкәтне алуны раслый торган документлар әзерләү һәм аларның милекчеләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә аерып алынган өчен компенсация түләүләре алырга бирү;

аерып алу, утильләштерү, юк итү нәтиҗәләре буенча беренчел исәпкә алу документациясен (актларны) төзү;

авыруны профилактикалау буенча, чикләүче чараларны үтәү кагыйдәләре турында, шулай ук хайваннарны (кошларны) аерып алган өчен акчалата компенсацияләр түләү тәртибе турында халыкка хәбәр итү һәм аңлату эшләре алып бару;

## III. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының оештыру структурасы бурычлары һәм җиһазландырылуы

1. Отряд турында Нигезләмә һәм аның оештыру структурасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән раслана.

Отряд командиры булып «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУсе начальнигы (җитәкчесе) тора.

2. Отряд функциональ бүлекчәләрдән тора (төп һәм тәэмин итү).

Төп бүлекчәләр:

ветеринария разведкасы төркеме;

аерып алу төркеме;

кыргый хайваннарның (кошларның) санын көйләү төркеме;

утильләштерү төркеме;

дезинфекция төркеме.

Тәэмин итү бүлекчәләре:
медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме;
үткәрү режимын тәэмин итү төркеме;
җәмәгать тәртибен саклау төркеме;
табиб-шәфкать туташлары бригадасы;
янгын бүлекчәсе;
санитар-юдыру пункты.

3. Ветеринария разведкасы төркеме үлгән (авыру) хайваннарны (кошларны) ачыкланган (табылган) урынына чыгып, патологик материал сайлап алуны (патологик материалдан һәм биоматериалдан кан сывороткасы алу тәртибе буенча инструкция нигезендә), аны махсуслаштырылган лабораториягә илтүне (хайваннарның (кошларның) авыруларын тикшеренү өчен пробалар бирү тәртибе нигезендә) һәм үлгән хайваннарны ачыклау (табу) өчен янәшәге ишегалларны һәм территорияләрне әйләнеп чыгуны (тикшерүне) башкара, һәлак булган хайваннарны (кошларны) исәпкә алуны алып бара.

Төркем имин булмаган пунктка хайваннар (кошлар) үлгән (авыру) очраклар турында мәгълүмат алганнан соң бер сәгать эчендә чыга.

Төркем «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУсе хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Ветеринария разведкасы төркеме командиры отряд командиры урынбасары булып тора.

Төркемнең шәхси составы индивидуаль саклану костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру: патологик материалны алу инструментлары, патологик материалны транспортировкалау өчен хладоагентлы термоконтейнер, лабораториягә патологик материал юнәлтү бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклар, дезинфекцияләү чаралары, кул юу өчен су тутырылган савыт, сөлге, сабын, бинокль, фонарь, үлгән хайваннарны исәпкә алу журналы (кошлар).

4. Аерып алу төркеме авыру һәм контактта булган хайваннарны (кошларны) аулауны гамәлгә ашыра, кирәк булганда аларны кансыз рәвештә йоклату (эвтаназия), шулай ук үләксәләрне җыю һәм транспортка төяү чараларын үткәрә, утильләштерү урыннарына алып китә һәм үлгән хайваннарны (кошларны) исәпкә ала, аерып алу, тартып алу һәм юкка чыгару (утильләштерү) нәтиҗәләре буенча беренчел исәпкә алу документациясен (актларны) төзи, тартып алуны раслый торган документларны әзерли һәм аларны хуҗаларына компенсация түләүләре алу өчен бирә.

Төркем Биектау муниципаль районының “Дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУсе, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсенең исәпкә алу һәм хисап бүлеге хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: тоту өчен ятьмә (сачоклар), полиэтилен капчыклар, йоклату чаралары, шприц-автоматлар, үтерелгән хайваннарны (кошларны) исәпкә

алу һәм үлчәү журналлары, идән платформалы (амбар) үлчәве, калькулятор һәм дезинфекция чаралары, документлар (актлар) бланклары.

5. Кыргый хайваннарның (кошларның) санын көйләү төркеме кыргый фаунада контактта булган яки авыру хайваннарны (кошларны) аулауны (атуны) гамәлгә ашыра, аларны җыю һәм транспортка төяү чараларын үткәрә, ауланган, атылган һәм үлгән хайваннарны (кошларны) исәпкә ала һәм аларны лаборатор тикшеренүгә илтә.

Төркем Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының биологик ресурслар буенча дәүләт күзәтчелеге буенча Биектау бүлеге хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: чехолларда ау мылтыклары, аучы пычаклары, амуниция (патронташ, кейслар һ.б.), тоту өчен ятьмәләр (сачоклар), хайваннар (кошлар) мәетләре өчен полиэтилен капчыклар, атылган кыргый хайваннарны (кошларны) ату урыннарын һәм табу урыннарын теркәп исәпкә алу журналы.

6. Утильләштерү төркеме утильләштерү урынын әзерли, мәетләрне утильләштерү урынында бушата, дезинфекция чараларын кулланып, биотермик чокырларда хайваннар (кошлар) үләксәләрен (түшкәләрен) утильләштерә яки янгын куркынычсызлыгы һәм шәхси куркынычсызлык чараларын катгый үтәп яндыру юлы белән утильләштерелә, утильләштерелгән хайваннарны (кошларны) исәпкә ала.

Төркем «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ һәм «Биектау коммуналь челтәрләре» ААҖ хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Төркем составыннан ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясенең ветеринария табибы терлек сую продуктларына (кошларга) ветеринария-санитария тикшерүе һәм ит продуктларына ветеринария-санитария экспертизасы кагыйдәләре нигезендә ветеринария-санитария экспертизасы уздыра.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: металл кузовы булган экскаватор һәм йөк автомобиле (яки металл савытлы автомобиль), дезинфекцияләү чаралары, утильләштерелгән хайваннарны (кошларны) исәпкә алу журналы.

7. Дедезинфекция төркеме үлгән (авыру) терлекләрне (кошларны) ачыклау урынын,инфекция учагында агымдагы һәм соңгы дезинфекцияне, механик чистартуны үткәрә (ветеринария дезинфекциясе, дезинвазия, дезинсекция һәм дератизация үткәрү инструкциясе нигезендә).

Төркем «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУсе хезмәткәрләре хисабыннан формалаштырыла.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә

Төркемне җиһазлау: Комаров дезинфекция җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

8. Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

эпизоотик (инфекция) учакта һәм якын-тирә территориядә медицина һәм эпидемиологик разведка;

хәтәрле төркеме затларына (эпизоотия учагын бетерүдә катнашкан отрядның һәм башка катнашучыларның шәхси составы) медицина каравы;

авыруларны ачыклау максаты белән ишегалларны йөреп чыгу һәм авырулар белән аралашучыларны һәм контакт дәрәҗәсен билгели;

авыруларга һәм инфекцияле авыру шиге булган затларга лаборатория тикшерүләре оештыру;

кирәк булганда ашыгыч профилактика оештыру;

авыруларны, авыруга шик булган затларны вакытлыча изоляцияләү;

эпидемия учагында агымдагы һәм йомгаклау йогышсызландыруны үткәрү һәм аның сыйфатын контрольдә тоту.

Төркем «Татарстан Республикасында (Татарстан) Арча һәм Биектау районнарында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУ филиалы һәм “Биектау ҮРХ” ДАССУсе хезмәткәрләре хисабыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру: лаборатор тикшеренүләр өчен материалны җыю өчен җайланма, медицина ярдәме күрсәтү өчен күчмә җайланма.

9. Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме ЧС зонасында (карантин) хәрәкәтне оештыра һәм җайга салуны тәэмин итә. Төркем ветеринар-полиция постларын (контроль-пропуск һәм санитар-пропуск) җиһазлау һәм урнаштыру өчен билгеләнгән.

Постлар саны карантин зонасына керү (чыгу) саны белән билгеләнә.

Төп керү урыннарында (карантин зонасына) контроль-пропуск постлары, патруль-пост хезмәте постлары булдырыла.

Төркем Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлеге һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе бүлеге (килешү буенча), "Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ (килешү буенча) хезмәткәрләре арасыннан төзелә.

Пунктны җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, кешеләрнең киемен алмаштыру урыны, Комаровның дезинфекция җайланмасы яисә транспорт чараларын махсус эшкәртү (дезинфекцияләү) өчен башка техника, эш эремәсе әзерләү өчен савыт, су өчен савыт, дезинфекция чаралары, юынгыч, сөлге, сабын, «Карантин» дип язылган аншлаг.

Постны җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, «Карантин» язулы аншлаг, ЧС (карантин) зонасын урап узуны күрсәткән юл билгеләре, фонарь.

Төркемнең шәхси составы сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

10. Җәмәгать тәртибен саклау төркеме карантин зонасында (ЧС зонасында) хокук тәртибен саклауны тәэмин итә, отрядның шәхси составын, беренче чиратта, ветеринария разведкасы төркемнәрен, аерып алу, медицина

һәм эпидемиологик разведка төркемнәрен озата баруны һәм саклауны оештыра.

Төркем Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлеге хезмәткәрләре арасыннан формалаша (килешү буенча).

Төркемнең шәхси составы штаттагы корал һәм сулыш органнарын һәм тирене саклауның табель чаралары белән тәэмин ителә һәм җиһазландырыла.

11.Табиб-шәфкать туташлары бригадасы карантин-чикләү чараларын уздыру чорында отрядның шәхси составына медицина каравы, аның сәламәтлегенә контроль, кирәк булганда, ачыкланган (шикле) авыруларны йогышлы авырулар бүлегенә госпитализацияләүне оештыра.

Бригада «Биектау ҮРХ» ДАССУсе хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Бригаданың шәхси составы саклау костюмнары, халатлары, баш киемнәре һәм маскалар белән тәэмин ителә.

Бригаданы җиһазландыру: медицина ярдәме күрсәтү өчен табиб (фельдшер) җайланмасы һәм Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкче документлары таләпләре нигезендә башка табель мөлкәте.

12. Янгын бүлеге үлгән һәм үтерелгән хайваннарны (кошларны) яндырганда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

Бүлекчә командиры яндыру урынын сайлауда катнаша. Янгын чыккан очракта аны сүндерүне оештыра һәм үткәрә.

Янгын бүлеге Россиянең Татарстан Республикасы буенча 113 ПСЧ 7 ПСО ФПС ГПС ГУ МЧС хезмәткәрләре составыннан формалаша..

13.Санитар-юдыру пункты шәхси составны һәм мөлкәтне санитар эшкәртү үткәрә.

Пункт «Биектау коммуналь челтәрләре» ААҖ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Хайваннар һәм кешеләр авыруларын локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексы тәмамланганнан соң, отрядның шәхси составы һәм карантин зонасында

эшкә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри санитар эшкәртү уза, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус кием яндыру юлы белән юк ителә.

Пунктны җиһазлау: Комаров дезинфекцияләү җайланмасы, күчмә душ җайланмалары, су савыты, сабын, сөлге, утын.

## IV. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды командирының вазыйфалары

1.Отряд командиры гадәттән тыш хәлләрне (эпизоотияне) бетерү чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы һәм отрядның барлык шәхси составы өчен турыдан-туры җитәкче булып тора.

Ул әзерлек, дисциплина, йөкләнгән бурычларны вакытында һәм сыйфатлы үтәү, отрядның бүлекчәләрен (төркемнәрен) шәхси состав белән комплектлау, техника һәм милек белән тәэмин итү өчен шәхси җаваплы.

Отряд командиры муниципаль берәмлекнең Башкарма комиеты җитәкчесенә буйсына.

2. Отряд командиры бурычлы:

инфекция учагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкче документларның таләпләрен белү һәм аларга үз эшчәнлегендә таяну;

отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшләүдә һәм корректировкалауда катнашырга;

йөкләнгән бурычларны үтәгәндә отрядның шәхси составы белән җитәкчелек итәргә; отрядның шәхси составын белергә, аның бурычларын, мөмкинлекләрен, шәхси составны туплау, техниканы һәм барлык милек төрләре белән җиһазлау тәртибен белергә;

буйсынудагы кешеләрнең эпизоотияне кисәтү һәм бетерү буенча махсус әзерлек дәрәҗәсен, әхлакый һәм эшлекле сыйфатларын белергә;

эпизоотик учакны локальләштергәндә һәм юк иткәндә, отрядның җыелу һәм урнашу урыннарын белергә;

отряд белгечләренең шәхси әзерлеген даими камилләштерергә, отрядның шәхси составы белән махсус әзерлек буенча дәресләр оештырырга һәм уздырырга;

отрядның гамәлләргә әзерлеген яхшырту чараларын үткәрергә, шәхси составның даими әзерлеген тәэмин итәргә;

куелган бурычларны үтәүгә ирешергә, акыллы инициатива күрсәтергә һәм карарлар кабул итәргә;

мөлкәтне һәм махсус техниканы дөрес куллануны, аларны карап тотуны һәм саклануын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

отрядның шәхси составын индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итү турында кайгыртырга;

җирле үзидарә органнары белән үлгән һәм үтерелгән хайваннарны (кошларны) утильләштерү урыннарын килештерергә;

эшләр (чаралар) тәмамлангач, шәхси составны санитар эшкәртүне, техниканы, мөлкәтне һәм җайланмаларны дезинфекцияләүне оештырырга;

ЧСны бетерү (эпизоотия) буенча оператив штабка инфекция учагын локальләштерүгә һәм юкка чыгаруга җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар составы турында, эпизоотия районындагы вәзгыять турында, эшләр (чаралар) башкаруның барышы турында мәгълүматны үз вакытында тапшырырга;

эшләр (чаралар) үткәрү өчен җәлеп ителә торган көчләр һәм чаралар составын үзгәртү (төркемнәрне үзгәртү) буенча үз вакытында карарлар кабул итәргә, аларны Башкарма комитет җитәкчесе белән килештерергә;

Биектау муниципаль районының КЧС һәм ОПБ рәисенең эпизоотия белән бәйле гадәттән тыш хәлләр ЧС режимы кертелү турында карарын эшләү өчен тәкъдимнәр кертү;

отряд бүлекчәләренең ихтыяҗларын билгеләү һәм белү һәм отряд өчен тиешле матди һәм дезинфекция чараларын вакытында сорап алырга;

матди чараларны исәпкә алуны, саклауны һәм куллануны контрольдә тотарга;

отрядның шәхси составы белән елга кимендә бер тапкыр тренировкалар үткәрергә;

отрядның шәхси составы өчен куркынычсызлык таләпләрен билгеләргә һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга, эшләр (чаралар) уздырганда аларны тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә һәм идарәнең башка югарырак органнарына уздырылган чаралар турында хисаплар һәм хәбәрләр тапшырырга.

## V. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды белгечләренең функциональ вазыйфалары

Отряд белгечләренең функциональ вазыйфалары отряд командиры тарафыннан аның составына керүче бүлекчәләр (төркемнәр) командирлары белән берлектә эшләнә һәм, отряд эшчәнлегенең төрле режимнарында биологик (ветеринария, эпизооти) торышның мөмкин булган сценарийларыннан чыгып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

## VI. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын әзерлеккә китерү Тәртибе

1. Отряд Биектау муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары (күрсәтмәсе) буенча әзерлеккә китерелә.
2. ЧС (карантин) зонасында эшләү өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составын Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - отряд командиры тәкъдиме буенча районның КЧС һәм ОПБ рәисе билгели һәм гадәттән тыш хәлнең таралуын китереп чыгарган һәм хәл ителә торган мәсьәләләрнең күләменә бәйле.
3. Отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю өчен «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУсе буенча дежур торучы өчен инструкция эшләнә һәм раслана.
4. Сигнал алу моментыннан әзерлеккә китерүгә гомуми вакыт түбәндәгечә:

эш вакытында: отрядка - 2 сәгатьтән артык түгел, ветеринар разведка төркеменә – бер сәгатьтән артык түгел;

эштән тыш вакытта: отрядка - 4 сәгатьтән артык түгел, ветеринар разведка төркеменә - 2 сәгатьтән артык түгел.

5. Отряд командиры отрядны әзерлеккә китерү буенча чаралар тәмамлангач Башкарма комитет җитәкчесенә хәбәр итә.

## VII. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының эшләү режимы

1.Биектау муниципаль районы территориясендә биологик (ветеринария, эпизоотик) торышка бәйле рәвештә, отряд түбәндәге эшләү режимнарының берсе билгеләнә:

югары әзерлек режимы - хайваннарның (кошларның) үлүе ачыкланганнан алып диагноз куелганга кадәр (хәл ителә торган мәсьәләләрнең беренче этабына туры килә);

биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәл режимы (алга таба - эпизоотия режимы) - авыру һәм аны тарату куркынычы булуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә чикләү чаралары (карантин) билгеләп, аларны урнаштыру режимы (башкарыла торган бурычларның икенче этабына туры килә).

## VIII. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының шәхси составын әзерләү

1. Отрядка кергән белгечләр штаттагы вазифалар буенча эшләү тәҗрибәсенә ия булырга тиеш.

2. Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп методлары булып инструкторлык-методик дәресләр, гамәли күнекмәләр, өйрәнүләр тора.

3. Шәхси состав белән инструктор-методик дәресләрдә куркынычсызлык чараларын үтәү, беренче чиратта, эпизоотик (йогышлы) учакта эшләгәндә шәхси составны инфекцияләнүдән профилактикалау мәсьәләләренә, сулыш органнарын һәм тирене индивидуаль саклау чараларыннан файдалану кагыйдәләренә аерым игътибар бирелә.

4. Отрядның шәхси составы белән инструкторлык-методик дәресләрне бүлекчә командирлары үткәрә, тренировка һәм өйрәнүләрне – отряд командиры.

5. Отрядның шәхси составы әзерлеге өчен отряд командиры җавап бирә.

## IX. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының материаль-техник һәм финанс белән тәэмин ителеше

Отрядны материаль-техник һәм финанс белән тәэмин итү Биектау муниципаль районының тиешле функциональ бүлекчәләрен (төркемнәрен) һәм чараларын булдыручылар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Эпизоотия режимында эшләү өчен билгеләнгән һәм көндәлек эшчәнлектә файдаланылмый торган лаборатор җиһазлар, реактивлар, саклану чаралары, дезинфекция һәм башка чаралар запаслары, отряд командиры карары нигезендә махсус биналарда саклана, төзек хәлдә тотыла һәм билгеләнгән тәртиптә яңартыла.

## X. Биектау муниципаль районы эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының документлар исемлеге

1. Отрядта документларның мәҗбүри исемлеге төзелә, ул отряд командирында саклана.

2. Отряд документларының дөрес рәсмиләштерелүе һәм алып барылуы өчен отряд командиры җаваплы.

3. Отряд документларының исемлеге:

эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд оештыру һәм комплектлау турында Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары;

отрядның оештыру-штат структурасы;

отрядның шәхси составы исемлеге;

отряд составына кертелә торган автомобиль техникасы исемлеге;


отрядны шәхси составына хәбәр итү схемасы;

«Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУсендә дежур торучыны (отряд дежурные) отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю буенча инструкцияләү.

4. Шәхси состав буенча белешмәләрне төгәлләштерү (корректировкалау) ярты еллыкта кимендә бер тапкыр, шулай ук өйрәнүләр, күнегүләр һәм оештыру-штат чараларын үткәрү алдыннан уздырыла.

2 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 нче елның 17 нче мартындагы
291 нче номерлы

Оештыру-штат структура




Барлыгы: шәхси состав - 59 кеше һәм күбрәк, техника - 17 бер. һәм күбрәк.

Примечание: МО* - муниципальное образование;
** - в зависимости от количества въездов (выездов) в населенный пункт (объект, зону ЧС, карантина).